УДК 355.292.3

*Г.М. Дәүләтшин*

# ФРОНТ ҺӘМ ФӘН ЮЛЫН УЗГАН ГАЛИМНӘР

В статье дается обзор жизни и научной деятельности ученых-фронтовиков, трудившихся после Великой Отечественной войны в ИЯЛИ: Я. Абдуллина, Ш. Абилова, Б. Гиззата, А. Каримуллина, И. Надирова, М. Мухарямова, Г. Юсупова и др. Опираясь на источники разного характера и личные воспоминания, автор описывает боевой путь и военные подвиги своих коллег, воспроизводит их жизненный путь как выдающихся личностей и авторитетных научных деятелей, создает своеобразный коллективный портрет поколения ученых-фронтовиков. Очерчиваются основные направления их деятельности, устанавливается вклад каждого из них в татарскую гуманитарную науку, перечисляются знаковые труды, актуальные для исследователей по сей день.

**Ключевые слова:** ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, Великая отечественная война, ученые-фронтовики, татарская гуманитарная наука, воспоминания.

The article provides an overview of the life and scientific activities of front-line scientists who worked at the Institute of Language, Literature, and History after the Great Patriotic War: Ya. Abdullin, Sh. Abilov, B. Gizzat, A. Karimullin, I. Nadirov, M. Mukharjamov, Kh. Yusupov and others. Relying on various sources and personal recollections, the author describes the military path and feats of his colleagues, reproduces their life path as outstanding individuals and authoritative scientists and creates a collective portrait of the generation of front-line scholars. The main areas of their activity are outlined and each of them is credited with their contribution to Tatar humanitarian science. The article also lists notable works that are still relevant for researchers today.

**Keywords:** G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and History, Great Patriotic War, front-line scholars, Tatar humanitarian science, memoirs.

Бөек Ватан сугышы чоры совет халкы өчен дәһшәтле, авыр сынау буларак тарихка кереп калды. Җәмгыятьнең бөтен өлкәләренә тәэсир иткән кебек үк, фәнгә дә сугышның йогынтысы зур булды.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ул вакытта Тел, әдәбият һәм тарих татар фәнни-тикшеренү институты) сафларын фронт авырлыкларын үз җилкәләрендә татыган, яраланып, кабат сафка баскан, инде шактый тормыш тәҗрибәсе туплаган, ил язмышы, халык тарихы һәм мәдәнияте белән тирән кызыксынган фронтовиклар тулыландыра.

Фронт юлын лаеклы узып, озак еллар Тел, әдәбият һәм тарих институтында хезмәт иткән галимнәрнең саны дистәдән артып китә. Аларның һәрберсенең фәнгә алып килгән үз юлы, үз тарихы бар. Сугыштан соңгы чорда дистә еллар дәвамында ветераннарга карата җылы мөгамәлә, ихтирам хисе һәрдаим сакланып килде. Бу хакта шәхсән үзем күреп тә, төрле елларда төшкән, Институт архивында

сакланган фотосурәтләрдән чыгып та һич шикләнми әйтә алам. Әлеге мәкаләнең максаты – агымдагы Ватанны саклаучылар елында һәм Бөек Ватан сугышында җиңүнең 80 еллыгын билгеләп узган көннәрдә фронтовик галимнәрне искә алу.

Казан дәүләт университетының СССР тарихы кафедрасында археолог А.Х. Халиков җитәкчелегендә аспирантураны тәмамлаганнан соң, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни архив җитәкчесе итеп билгеләндем. Архив татар тарихы һәм мәдәниятенә, борынгы кульъязмаларга, аерым шәхси фондларга бай иде. Биредә бик күп шәхесләр белән танышырга, аларның фикерләрен, истәлекләрен тыңларга мөмкинлек туды. Ике елдан соң, коллективның профком (ул вакытта местком) рәисе итеп сайландым. Бу җәмәгать вазифасын 6 ел (1979–1983 һәм 1987–1989) башкарырга туры килде. Шулай итеп, яңарак кына эшкә килгән, әле тәҗрибәсез, шактый дәрәҗәдә романтик рухлы яшь егеткә коллективка якынаю, байтак кешенең хәл-әхвәле белән танышу мөмкинлеге туды.

Шактый катлаулы елларда оешкан, кайчак тетрәнүләр кичергән (ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августындагы «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы, Татарстан өлкә комитеты бюросының 1944 елның 6 сентябрендәге «Татар тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының эше һәм хаталары турында» карарлары гына да ни тора!) бу Институтта һәрберсе аерым игътибарга лаек галимнәр эшли иде.

Сүземне Институтта элгәрерәк (әле оешкан гына вакытында ук) эшләгән шәхестән башлап китәм.

**Хәсән Габдрахман улы Шабанов** (1901–1956) хәзерге Пенза өлкәсенең Мачали авылында туа. Ул – ике сугыш ветераны, Гражданнар сугышында да катнашкан.

Хәсән 1923 елда үз авылында мәктәп ача, 1932 елда Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый. Алга таба Казандагы 80 нче татар мәктәбен җитәкли. Аннан шәһәр мәгариф бүлеге мөдире итеп күчерелә. 1939–1941 елларда Х.Г. Шабанов – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры. 1943 елда фронтка җибәрелә. Өлкән лейтенант Шабанов Берлинга кадәр барып җитә. Җиңүнең икенче көнендә аны снайпер яралый. Госпитальдә дәваланып Казанга кайткач, Хәсән Шабановны Татарстан китап нәшриятына – өлкән, аннары баш редактор итеп куялар. Ул балалар өчен берничә җыентык бастырып чыгара.

Мин Институтка килгәндә, **Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов** (1922–1993) директор булып эшли иде.

Ул Башкорстанның татар әдәбиятына Дәрдемәнд, Мирсәй Әмир кебек классикларны биргән Җиргән авылында туа. 1940 елда 18 яшьлек Мидхәт, Казан элемтә техникумында укуын ташлап, Сызрань Танк училищесына керә, анда хезмәт итә. Хыялы – Кызыл армия командиры булу. Фронтка яшь танкист 1942 ел башында алына. СССР

өчен сугышның иң авыр чоры була бу. М. Мөхәррәмов, танкта каты пешеп, госпитальгә эләгә, ләкин 1942 елның декабрендә яңадан сафка баса. Курск сугышы вакытында ул элемтә офицеры булып хезмәт иткән корпус зур батырлыклар күрсәтә һәм гвардия корпусы була. Әмма 1944 елның гыйнварында гвардия капитаны М.К. Мөхәррәмовның, каты яралану сәбәпле, героик юлы өзелә, хәрби карьерасына нокта куела. Аны авыр хәлдә Ташкент госпиталенә җибәрәләр. Ике аягы да нык яраланган була. Биредә аңа уң аягын ампутацияләү белән килешергә туры килә.

Мидхәт Мөхәррәмов 1948 елда Казанда юридик институтны бишле билгеләренә генә тәмамлый. Әмма күңеле белән тарих фәненә тартыла. Ул 1951 елдан Тел, әдәбият һәм тарих татар фәнни-тикшеренү институтына эшкә кереп, гыйльми сәркатип вазифасын башкара, аннан тарих бүлеген җитәкли. Тарихчы, тарих фәннәре докторы (1964), профессор (1967), ТАССРның, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1972, 1982), Ленин, I һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, ике тапкыр Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов 18 ел (1963–1982) дәвамында Тел, әдәбият һәм тарих институтын җитәкли. Совет чоры кысаларына карамастан, Мидхәт Кәрим улы иң беренче чиратта Институт хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән хезмәтләрнең сыйфатына, архивларда күп эшләүче галим буларак, аларның фактик материалларга нигезләнүенә игътибар итә.

Галимнең «Татарстан АССР тарихы» (икенче том), «Татариянең партия оешмасы тарихы турында очерклар», «Татарстанда Октябрь инкыйлабы һәм милли дәүләт төзелеше» кебек капиталь хезмәтләрне әзерләүгә керткән шәхси өлеше гаять зур.

М.К. Мөхәррәмовның ныклы дәлилләнгән сүзенә югары партия, хөкүмәт оешмалары да колак салалар иде.

Мидхәт Кәрим улы Институт хезмәткәрләренә хөрмәтле, сакчыл карашта булды. Берәрсе турында кыек сүз әйтелсә, җитәкче буларак, «бу безнең эш» дип, һәрчак аны яклап чыкты.

Хәтердә, Институтта даими рәвештә, аеруча Равил Әмирханов тырышлыгы белән, хезмәткәрләр тарафыннан яратып укылган «Фикер» исемле стена газетасы әзерләнә иде. М.К. Мөхәррәмов та аның белән танышып барды. Бервакыт ул андагы язмалар арасында күренекле галим Хәлиф абый Курбатов турында, шаяртып, аның авыруына ишарәләп язылган юлларны күреп, «Хәлиф Рәхимович укыдымы, ул бу шаяруны ничек кабул итәр икән? – дип борчылып сорап куйды.

Кабинетына кергән өлкәннәрне, аеруча хатын-кызларны, Мидхәт аганың, урыныннан торып, култык таякларына таянып каршы алуы истә калган.

Бөек Ватан сугышында катнашкан галимнәргә профком тарафыннан игътибар шактый зур иде. Әмма шунысы сәер: аларның профкомга ниндидер гозерләр белән мөрәҗәгать итүләрен хәтерләмим дә диярлек. Бер елны директорыбызга санаторий юлламасы белән кыенлык туганны ишетеп, янына кердем. Башкалар алдында бераз

шаяртып: «Менә Гамирҗан нәрсә әйтер?» – дип куйды. Мин югалып калдым: «Ничек инде, сезгә...» – дип кенә әйтә алдым.

Ул елларда зур бәйрәмнәрне бергә җыелып уздыру гадәткә кергән иде. Аларда М. Мөхәррәмов та актив катнаша: Институт эшендәге уңышлар, алда торган мәсьәләләр турында кыска гына чыгышыннан соң, коллективның күңелен күтәрерлек шаяртуларга күчә иде.

М.К. Мөхәррәмов 70 яшен тутырып вафат булды. Бу шәхесне якыннан белгән замандашлары аны хаклы рәвештә батырлык, намуслылык эталоны, күп кенә кешелек сыйфатларының гәүдәләнеше дип саныйлар. Күпләр, галимнең фәнни казанышларын күздә тотып, хезмәтләренең Ватан историографиясендә зур әһәмияткә ия булуын билгеләде. Өченчеләр аңа «тормышка юллама» тапшырганы, нәтиҗәле ярдәм күрсәткәне һәм тарихчы һөнәрен үзләштерүдә булышканы өчен чын күңелдән рәхмәтле булдылар, дип искә ала коллегасы Р.Г. Әмирханов.

Мидхәт Кәрим улы турында аның хезмәттәшләре тарафыннан күп кенә истәлекләр язылган (Әкъдәс Борһанов, Әлфия Галләмова, Равил Әмирханов һ. б. хезмәтләре). Галимнең тууына 100 ел тулуга багышлап, саллы гына «Памяти М.К. Мухарямова. История. Профессия. Судьба» (2022) исемле китап та дөнья күрде.

М.К. Мөхәррәмов җитәкчелек иткән вакытта ук, Институтта ул чор өчен исеме дә, җисеме дә ятрак булган иҗтимагый фикер тарихы бүлеге оештырыла. Аның җитәкчесе итеп, тиздән директор урынын да биләячәк **Яхъя Габдулла улы Абдуллин** (1920–2006) билгеләнә.

Я.Г. Абдуллин – философ, философия фәннәре докторы (1978), профессор (1981), ТР ФА шәрәфле әгъзасы (1995), Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе.

Я.Г. Абдуллин 1920 елда Теләче районының Олы Кибәхуҗа авылында туа. Аны 16 яшендә үк район газетасына эшкә алалар. Испаниядә сугыш башлангач, Яхъя, үзен Кызыл армия сафларына алуны сорап, СССР Оборона халык комиссары Климент Ворошиловка хат яза. Финляндия белән сугыш башлангач, ул бу үтенечен җирле хәрби комиссариатка җибәрә. Егетнең теләге 1941 елны гына тормышка аша. Берничә мәртәбә яраланса да, ул сугышның иң дәһшәтле бәрелешләрендә: Сталинград оборонасында, Ленинград блокадасын өзү, Европаны азат итү һәм Берлинны алу өчен барган сугышларда катнаша. I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, ике Кызыл Йолдыз ордены һәм 15 медаль белән бүләкләнә. Кызы Айгөлдә саф татарча язылган, берничә дәфтәрдән торган сугыш көндәлекләре саклана. Язмаларның бер өлеше басылып чыкты инде. Алар шактый дәрәҗәдә җентекләп язылган. Мәсәлән 1945 елның 2 маенда ул болай дип яза: «Ниһаять, 2 майда Берлин капитуляцияләде. Кояшлы көн. Җылы. Без урамнарга ташланабыз. Шпрее ярындагы бер паркка чыктык. Агачлар яфракларда, чәчәкләрдә. Безнең йөрәкләрдә дә шатлык. Паркка немец хатын-кызлары да чыкты, Интернационалны җырлыйлар, мөгаен, безгә ярарга тырышып. Ә паркта җимерек йортлар. Берлин хәрабәләр эчендә».

1986 елда мине фәнни архивтан Яхья Габдулла улы эшләгән иҗтимагый фикер тарихы бүлегенә күчерделәр. Я. Абдуллин талантлы, тырыш яшьләрдән торган коллектив туплаган иде. Ул вакытта ук күпләргә билгеле Ә.Г. Кәримуллинның да әлеге бүлектә эшләве нур өстенә нур булды, яшьләр белән өлкәннәр арасындагы эшлекле баланс булдырылды.

Күп еллар партия оешмаларында эшләвенә карамастан, Яхъя Габдулла улы гуманитар фәннәр өлкәсендә «Татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихы» дигән фәнни юнәлешкә нигез сала, аның концепциясен булдыра, бу өлкәдә ислам дине һәм мәдәниятенең дә урынын билгели. Галим фәлсәфи, иҗтимагый-сәяси, тарихи, хокукый, әхлакый-этик һәм эстетик карашлар системасы буларак мәгърифәтчелек хәрәкәтенең эчтәлеген ача. Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Шәмсетдин Күлтәси кебек зыялыларның тормышына, иҗатына, иҗтимагый-фәлсәфи мирасына тәфсилле характеристика бирә. Я.Г. Абдуллин татар иҗтимагый фикере тарихының җәдитчелек кебек катлаулы күренешенә фәнни тарихи-фәлсәфи анализ ясый.

Галимнең татар мәгърифәтчелеген фәнни яктан өйрәнүе нәтиҗәләре «Татарская просветительская мысль: (Социальная природа и основные проблемы)» (1976), «Мәгърифәт яктылыгы», «Милләт язмышы: уйланулар» (2000), «Ислам һәм аның татар халкы тормышында урыны» китапларында һәм фәнни басмаларда дөнья күргән мәкаләләр сериясендә (Мәгърифәт нуры ачар..., 1987; Джадидизм среди татар. Возникновение, развитие и историческое место, 1998 һ. б.) чагылдырыла.

Я.Г. Абдуллин бүлек мөдире, Институт директоры булган елларда уздырылган семинарларда бик күп яңа, кызыклы фикерләр әйтелә. Бу фикерләр соңрак Татарстан, Россия күләмендә дә яңгырый башлый. Яхъя Габдулла улы үз фәнни мәктәбен булдыруга ирешә. Бүлек җитәкчеләре буларак Ф.М. Солтанов, Р.М. Әмирханов аның эшен уңышлы дәвам итәләр.

**Җәмил Ибраһим улы Гыйльманов** (1925–1991) – тарих фәннәре докторы, профессор, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре – 1925 елның 3 июлендә хәзерге Самара өлкәсенең Кошкин районы Теплый Стан авылында укытучылар гаиләсендә туа.

1943 елда ул Кызыл армия сафларына алына. Икенче Орджоникидзе (хәзер Владикавказ) хәрби-пехота училищесына укырга керә. Аннан соң 1945 елның мартында фронтка эләгә һәм укчылар ротасы командиры итеп билгеләнә. Аның подразделениесе хәрәкәттәге 4 нче Украина фронтында Польша, Чехословакия, Германияне фашистлардан азат итүдә катнаша.

Училищеда ук гомерлек дустына әйләнгән полковник Дмитрий Азов Җ. Гыйльмановның батырлыгы, хәрби осталыгы турында үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «З.И. Гильманов годился своим

подчиненным в сыновья, но по должности был старшим офицером, их командиром. Неторопливо и деловито подавал команды. Голос у него уверенный. Мины летели в цель... Зямиль прекрасно ориентировался на местности, обладал исключительной требовательностью к подчинённым. Решения принимал быстро и всегда обоснованно… В самый сложный момент З. Гильманов с миномётными расчётами подбирался почти вплотную к атакующим. И сам прямой наводкой бил по вражеским силам… Недавний выпускник училища получил тогда за один из таких боев первый орден Красной Звезды».

Җәмил Ибраһим улы сугышта күрсәткән батырлыклары өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Германияне җиңгән өчен» һәм «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Ул сугыш көндәлеге алып бара.

Чехословакиянең Вратимов шәһәрен фашистлардан азат иткәндә күрсәткән батырлыгы өчен, чех партизаннары Җ.И. Гыйльмановны 30 ел узгач эзләп табалар. Бу очрашудан соң аңа «Вратимов шәһәренең Мактаулы гражданины» исеме бирелә. Күп еллар үткәч тә, ветеранга бу чех шәһәре кешеләреннән рәхмәт хатлары килә.

Җ.И. Гыйльманов 1945 елда японнарның Квантун армиясенә каршы маньчжур операциясендә катнаша, аннан соң илнең Чукоткадагы дәүләт чикләрен сакларга калдырыла. Галим андагы хезмәтнең бик авыр шартларда булуын ассызыклый (*Шишкина Д.* Зямиль Ибрагимович Гильманов: военные страницы биографии // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2006).

Җәмил Гыйльманов, Казан университетын тәмамлаганнан соң, (1952) КПССның Яшел Үзән шәһәр комитетында лектор булып эшли. 1958–1962 елларда Казан авиация институтында укыта, бер үк вакытта Бөтенсоюз «Белем» җәмгыятенең Татар бүлеге идарәсе рәисе урынбасары була. 1962–1964 елларда «Татарстан коммунисты» журналы баш мөхәррире һәм башка журналларның редколлегия әгъзасы вазифаларын башкара.

1964–1990 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлеге мөдире була. Чирек гасырдан артык ул җитәкләгән бүлектә М.К. Мөхәррәмов, Х.Х. Хәсәнов, С.Х. Алишев, Р.Г. Фәхретдинов, Ю.И. Смыков, Р.Г. Әмирханов, К. Нәҗипова кебек галимнәр эшли. Бу чорда тарих бүлеге элекке төбәкчелек тарихыннан югары профессиональ тарих язу дәрәҗәсенә ирешә. Хәрби хезмәттә, сугыш елларында ук формалашкан тугры дуслык эталоны Гыйльманов һәм Мөхәррәмов мөнәсәбәтләрендә дә сизелеп тора иде. Хезмәттәшләре Җәмил Ибраһим улын аталарча кайгырта белүче җитәкче буларак искә алалар.

Җ.И. Гыйльманов, Татарстан тарихчыларыннан беренче булып, республиканың Икенче бөтендөнья сугышы елларындагы Җиңүгә керткән гомуми өлешен, тылда һәм фронттагы хезмәт һәм сугышчан батырлыкларны комплекслы рәвештә ачып сала. Галимнең «Татария в годы суровых испытаний 1941–1945 гг.», «Трудящиеся Татарии на

фронтах Великой Отечественной войны» исемле китаплары дөнья күрә. Ул – «Татарстан АССР тарихы (борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр)» хезмәте авторларының берсе. Аның «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» дигән китабы, тагын уннан артык җыентыгы бар. Җәмил Гыйльманов шулай ук өч томлы «Герои Советского Союза – наши земляки», «История Казани» (ике томда) һәм башка коллектив хезмәтләрне бастыруда актив катнаша. Берничә китап (шул исәптән безнең республикада тупланган бер дивизиянең сугышчан юлы турында) аның авторлыгында да чыгарыла. Ул Советлар Союзы герое Дмитрий Карбышевның чыгышы белән татар булуын ачыклый. Үзе сугыш кичкән командирның бу хезмәтләре тагын да ышанычлырак булып кабул ителә.

Институтның тагын бер ветераны – **Фәтхелбәян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин** (Бәян Гыйззәт) (1918–1991). Ул 1918 елның 16 июлендә хәзерге Башкортстанның Кушнаренко районы Талбазы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1934 елда Уфага барып, Башкорт дәүләт медицина институтының рабфагына укырга керә. Әмма аны тәмамлагач, матур әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт аны Казан дәүләт педагогика институтына алып килә. 1941 елда егетне аспирантурада калдыралар.

Бөек Ватан сугышы башлана. 1941 елның декабрендә Бәян Гыйззәт Ватанны саклаучылар сафына баса. Көнбатыш, Өченче Белоруссия фронтларында барган канлы бәрелешләрдә катнаша, яралана, госпитальдә дәваланып чыккач, хәрби училищега укырга җибәрелә. Офицер званиесендә ул яңадан фронтка китә. Курск дугасы янындагы мәгълүм канкоешларны исән-имин кичеп, Кенигсбергка кадәр сугышчан юл уза. Фронттагы батырлыклары өчен Бәян Гыйззәт ике мәртәбә Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

1945 елда сугыштан кайткач, Б. Гыйззәт Татар дәүләт академия театрына әдәби бүлек мөдире булып эшкә керә. Шул ук елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада да укый һәм 1951 елда «Гафур Коләхмәтевнең иҗаты» дигән темага диссертация яклый. 1953 елдан башлап, ул – Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре. 1968 елда Фәтхелбәян Гыйззәтуллин сәнгать бүлегенә нигез сала. 1981 елга кадәр бүлек мөдире була. Анда театр тарихы буенча гына түгел, ә бәлки музыка, декоратив сәнгать төркемнәре дә оеша. Биредә И.И. Илялова, М.Н. Нигъмәтҗанов, Д.К. Вәлиева, Д.Ә. Гыймранова, М.Г Арсланов, Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова кебек белгечләр зур фәнни казанышларга ирешә.

Бәян Гыйззәтнең әдәби-фәнни эшчәнлеге тулысынча диярлек татар драматургиясе һәм татар театр сәнгате белән бәйле. Аның драматургия һәм театрга кагылышлы тикшеренүләре «Егерменче йөз башында татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960), «Заман сулышын тоеп» (1967), «Татар совет театры» (1975), Мәскәүдә рус телендә чыккан «История татарской советской литературы»

(1965), «История многонациональной советской литературы» (1972) исемле китапларда урын ала. Таҗи Гыйззәт иҗатын яктырткан монографиясе 1957 елда аерым китап булып басылып чыга. Мәскәүдә Сәнгатьләр тарихы институтында әзерләнгән «История советского драматического театра» исемле алты томлы коллектив хезмәттә дә ул, авторларның берсе һәм редколлегия әгъзасы буларак, татар театрының үсеш этапларын яктырткан фәнни очерклары белән катнаша. Болардан тыш, Бәян Гыйззәтнең драматургия һәм театр сәнгате турындагы мәкалә һәм очерклары төрле җыентыкларда, әдәбият һәм театрга бәйле белешмә-энциклопедияләрдә, көндәлек матбугат битләрендә күпләп басылган. Галиәсгар Камал, Гафур Коләхмәтев, Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Мирхәйдәр Фәйзи, Хәлил Әбҗәлилов, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Гамир Насрый һ.б. бик күпләргә багышланган иҗади портретлар, аерым әсәр яки спектакльләр турында рецензияләр, сәнгатьнең бүгенге актуаль мәсьәләләрен күтәргән тәнкыйть мәкаләләре – болар һәммәсе Бәян Гыйззәтнең, галим һәм тәнкыйтьче буларак югары урыны, иҗат активлыгы турында сөйлиләр.

Фәнни-әдәби иҗат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Б. Гыйззәт «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә, шулай ук аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Б. Гыйззәт – 1957 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Үз гомерендә Бәян Гыйззәт күп тикшеренүләр алып бара. Аның әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланып, вакытлы матбугатта чыккан мәкаләләренең саны гына да 200 гә җитә. Ул җәмәгать эшендә дә актив катнаша. Язучылар берлегенең тәнкыйть секциясе җитәкчесе, Россия театр җәмгыяте әгъзасы була, шәһәр советы депутаты итеп сайлана.

Гыйззәтуллин Фәтхелбәян Нурлыгаян улы 1991 елның 25 маенда Казан шәһәрендә вафат була. Якын дусты, татар әдәбиятын укыту буенча күп хезмәтләр авторы Шамил Әхтәмов үзенең «Бәян Гыйззәт хатлары» исемле мәкаләсендә (Казан утлары, 1998, № 7) аны болай искә ала: «Минем күңелемдә Бәян һаман исән кебек. Озын буйлы, мәһабәт, төз гәүдәле Бәян, яшьләр шикелле җитез атлап, Ленин урамыннан Фәннәр Академиясенең Казан бүлегенә киләдер кебек. Бина алдындагы бакчада үткән гасырның атаклы математигы Лобачевский бюсты янынннан үтәр, йортка кергәч, хезмәттәшләре белән исәнләшер, хәл-әхвәл сорашыр, көнүзәк мәсьәләләр турында сөйләшер Фәтхелбәянның эш көне шулай башланып китә иде...».

Чираттагы ветеранныбыз – **Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин** (1925–2000). 1925 елның 25 маенда ТАССРның Мамадыш кантоны (хәзер Саба районына керә) Чәбия-Чурчи авылында туа. Әтисе Гыйбадулла Кәримулла улы – агроном, әнисе Сафия Гата кызы – авыл укытучысы. Ул 1930 елда күмәкләштерү чоры корбаны була. Башлангыч белемне Әбрар туган авылында, урта белемне Байлар Сабасын-

да ала. Мәктәпне тәмамлагач, ул туган авылында хисапчы, Нырты фабрикасы шифаханәсендә, аннары Олы Арташ авылында башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Хыялы – география укытучысы булу. Әмма теләген сугыш өзә.

1943 елда 18 яшьлек Әбрар Кәримуллин Кызыл армия сафларына алына һәм, «Житомир» хәрби училищесында алты айлык курсны тәмамлагач, минометчы буларак фронтка җибәрелә. Ул сугышкан данлы 110 гвардия укчы дивизиясе Бөек Ватан сугышының хәлиткеч бәрелешләрендә катнашып, махсус исемнәргә, югары сугыш орденнарына лаек була, Курск дугасы, Днепрны кичү сугышларында катнашып, Украина, Молдавия, Румыния, Венгрия, Чехословакияне фашистлардан азат итүдә данлы юл уза. Су асты машинасы белгече, разведка офицеры һәм миномётчы Ә. Кәримуллин батырлыклары өчен I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденына, ике тапкыр «Батырлык өчен» һ. б. медальләргә лаек була. 1944 елда, фронтта, Ә. Кәримуллин КПСС сафларына баса. Бөек җиңүдән соң, аны Ерак Көнчыгышка Японияга каршы сугышка җибәрәләр. Монда хәлләр тагын да авыррак була. Кытай, Монголиядә үлем үзәннәрен, Хинган таулары аша үтә, өч тапкыр яралана. Ниһаять, Ә. Кәримулин 1947 елда гына туган ягына кайта ала. Әтисе дә сугыштан яралапып кайта, озак тормый, шул яралардан 1947 елда вафат була. Әбрар тулы ятим кала.

Ә. Кәримуллин Саба районының Икшермә МТСында трактор бригадасында, «Ильич истәлеге» коллектив фермасында бухгалтер булып эшли.

1948–1953 елларда Ә. Кәримуллин КДУның Тарих һәм филология факультеты татар бүлегендә белем ала. Исемле стипендияләр алып укыса да, акча ашарга да җитми. Читтән ярдәмгә өмет юк. Аңа уку барышында һәм каникуллар вакытында эшләп көн күрергә туры килә.

Университетны тәмамлаганнан соң, 1953 елдан 1964 елга кадәр Әбрар Кәримуллин Казан университетының Фәнни китапханәсендә башта өлкән китапханәче, аннары бүлек җитәкчесе, фәнни эшләр буенча китапханә директоры урынбасары булып эшли. Андагы сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләренә караган гарәп шрифтындагы язма мираска бай була. Әмма тикшеренүчеләр өчен аларның эшкәртелмәве, тасвирланмавы фәнни өйрәнүләргә киртә булып тора. Татарлар революциягә кадәр китапсыз, грамотасыз халык булган, аларга уку-язуны совет хакимияте генә биргән, дигән ялган күрсәтмә дә моңа йогынты ясамый калмый. Ә.Г. Кәримуллин җитәкчелегендә гарәп графикасындагы татар китаплары рекаталогизацияләнә, ягъни каталог карточкаларын алыштыру белән бәйле китапханә каталогы тулысынча эшкәртелә, укучыга яңа тасвирлау нигезендә тәкъдим ителә. Нәтиҗәдә фәнни өйрәнү көчәя һәм бай рухи мирас кулланыла башлый. Автор һәм галимнәргә ислам һәм татар дөньясын өйрәнүдә зур мөмкинлекләр ачыла. Әбрар Кәримулин татар әдәбияты, әдәбият тарихы һәм белеме, халык

авыз иҗаты, Татарстан һәм татар халкы тарихыннан аерым-аерым күрсәткечләр төзеп, бастыра. Галимнең әдәби теория, лингвистика һәм библиография турындагы беренче мәкаләләре 1950 еллар башында ук вакытлы матбугатта чыга башлый. Шулай итеп, Ә.Г. Кәримуллин тарафыннан татар фәнни библиографиясенә нигез салына һәм үстерелә.

Бу елларда Ә.Г. Кәримуллин инициативасы белән һәм аның катнашында татарлар яшәгән республика, өлкәләргә даими рәвештә археографик эзләнүләр оештырыла башлый. Университет китапханәсе тагын да меңләгән татар, Шәрык кульязмалары белән байый. Моңа кадәр билгеле булмаган әсәрләр, исемнәр ачыла.

Ә.Г. Кәримуллин инициативасы белән китапханә Европа, Азия, Америка, Австралия кебек илләрнең 200 дән артык фәнни учреждение, югары уку йорты белән элемтә урнаштырыла, алардан китапханәгә, КДУ басмаларына китап алмашу тәртибендә, йөзләрчә һәм меңнәрчә китап, журнал, газета килә.

Әмма бу Татарстан, Россия җәмәгатьчелеге өчен, нигездә, көтелмәгән ачышлар бертөсле генә кабул ителми. Аеруча аның «Әдәби җыентык һәм альманахлар библиографиясе: 1917–1960» исемле хезмәтеннән соң, Сталинны, репрессияләнгән язучыларны, революциягә кадәр тудырылган язма мирасны күтәрүдә, панисламизмда һ. б. ларда гаепләп, Әбрар Кәримуллинга партия оешмалары тарафыннан каты шелтә белдерелә, «сәяси яктан җитлекмәгән хезмәткәр» буларак 1963 елда ул эшеннән алына.

Әбрар Гыйбадулла улы 1964–1992 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтының сәнгать һәм халык авыз иҗаты, татар иҗтимагый фикере тарихы бүлекләрендә эшли. Институтта ул татар театры тарихы буенча библиографик күрсәткеч төзү белән шөгыльләнә. 1968 елда «Татар сәхнәсе: 1917–1967 еллар» дигән монографик хезмәтен язып тәмамлый. Хезмәттә рус һәм татар телләрендәге 8 000 нән артык әдәбият исеме тәкъдим ителгән. Китапта Татарстанда һәм аннан читтә эшләгән барлык татар театрлары турында мәгълүмат тупланган. Бу үзенә күрә татар театры энциклопедиясе булды, Ватан библиографиясе практикасында аның аналоглары юк иде.

Иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә дә Әбрар абыйга карата ихтирамыбыз бик зур иде. Аз сүзле булса да, аның күпсанлы чыганаклар белән нигезләнгән төпле фикерләрен без көтеп ала идек. Ул 1976 елда университетта минем кандидатлык диссертациясе хакындагы фикер алышуда да катнашып, кыйммәтле фикерләрен җиткерде.

Әбрар Кәримуллин 1968 елда, КДУда «Татар басмасының барлыкка килүе һәм татар филологиясендә яңа чыганаклар: XVII – XIX гасырның беренче яртысы» темасы буенча кандидатлык, ә 1978 елда «XX гасыр башының татар китабы» фәнни хезмәте нигезендә Ленин исемендәге СССР дәүләт китапханәсендә докторлык

диссертациясе яклый. Бу диссертацияләр аспирантура үтмичә, фәнни җитәкчесез язылa.

1987 елда галим Татарстанның атказанган фән эшлеклесе булып таныла.

Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги: от начала возникновения до 60-х годов XIX века» (1992) трилогиясе Татарстанда гына түгел, илебезнең барлык почмакларында һәм чит илләрдә дә зур танылу яулый. Күренекле чит ил белгечләре аңа зур бәя бирде.

Ә. Кәримуллин трилогиясе беренче тапкыр татар басма сүзенең 1917 елга кадәрге тарихын комплекслы рәвештә өйрәнә, татар халкының рухи мирасын китап басу яссылыгы аша яктырта. Кәримуллин татарларның төрки телле халыклар арасында беренчеләрдән булып китап баса башлауларын раслый. Инкыйлабка кадәрге татар китабы, исем саны буенча рус һәм латыш китапларыннан гына калышып, ә тиражы буенча рус китабыннан соң икенче урында торып, татарларның югары грамоталы халык булуын раслый. Китап татар һәм башка мөселман халыкларын агартуга өлеш кертә, укучыларны татар басмалары аша дөнья әдәбияты әсәрләре, шул исәптән рус классиклары белән дә таныштыра. Галим татар китабы тарихына һәм биобиблиографиягә караган күпсанлы хезмәтләре өчен 1991 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1992 елда Татарстан Фәннәр академиясе оешуга, ул гуманитар фәннәр өлкәсендә, беренчеләрдән булып, хакыйкый әгъза (академик) булып сайлана.

Әбрар Гыйбадулла улы үз халкының килеп чыгышы һәм аның исеме тарихы белән бик кызыксына. «Татары: этнос и этноним» дигән хезмәт яза. Бу хезмәт өч тапкыр: татар һәм рус телләрендә 50000 артык тираж белән басылып чыга, япон, төрек, гарәп телләренә тәрҗемә ителә һәм укучыларда зур кызыксыну уята. Ул елларда бу китап һәр зыялы кешенең кулында булды.

Аның «Прототюрки и индейцы Америки. По следам одной гипотезы» (1995) китабы да сенсация буларак кабул ителә. Чит илләрдә дә, аеруча АКШта, яңгыраш таба.

Ә. Кәримуллин Татарстан һәм Россиянең күпсанлы гыйльми оешмаларында, гыйльми советларында, газета, журнал редакцияләрендә һ. б. әгъза булып тора. Ул 1978 елда атаклы тарихчы Л.Н. Гумилёв тәкъдиме белән Россия географик җәмгыятенә кертелә. Чит илләрдә дә аның абруе зур булды.

Ә.Г. Кәримуллинга АКШтагы Гарвард университетының фәлсәфә докторы исеме бирелә. Күп еллар буена ул Америка (Төньяк Каролина) биографик институты советы, Халыкара биографик берләшмәнең гомерлек, энциклопедик белешмәләрне бастырып чыгару буенча Халыкара биографик үзәкнең хакыйкый әгъзасы була һ. б.

Бу Әбрар Гыйбадулла улының эшчәнлегенә, хезмәтләренә югары бәя бирү генә түгел, ә бәлки татар дөньясының югары язма мәдәнияткә, цивилизациягә ия булуын да дөнья күләмендә тану иде.

Шушы көннәрдә Г. Камал театрының яңа бинасында Ә.Г. Кәримуллинның 100 еллык юбилеена багышланган кичә үткәрелде. Анда бөек галимнең тормыш һәм фәнни эшчәнлегенә багышланган «Беренче басма татар китабы эзләреннән» исемле фильм тамашачыларга тәкъдим ителде (режиссеры Нәсүр Йөрешбаев). Фикер алышуда катнашкан күренекле галимнәр, язучылар үзләренең чыгышларында Ә. Кәримуллинның югары дәрәҗәдәге универсаль галим булуы белән беррәттән, аның ялкынлы мәкалә, чыгышлары белән татар халкының мәнфәгатьләрен яклап көрәшүен дә билгеләп үттеләр.

Институт ветераннарын барлаганда, **Һарун Вәли улы Йосыповны** (1914–1968) да искә алу кирәк. Ул – күренекле археолог, эпиграфист, тарихчы, рухи мәдәният белгече.

Һ.В. Йосыпов 1914 елның 22 июнендә Казанда татар приказчигы гаиләсендә туа. Яшьтән үк әтисеннән гарәп телен, язуын өйрәнә. Әнисе Мәүгизә йорт эшләре белән шөгыльләнә, 5 баласын тәрбияли. Казанның 19 нчы мәктәбен тәмамлагач, аның хезмәт юлы башлана: хисапчы, электромонтер булып эшли һәм бер үк вакытта 1936–1941 елларда Казан университетының география факультетында укый, географ-геоморфолог белгечлеге ала.

1941–1942 елларда, татар геология-разведка трестында прораб булып берничә ай эшләгәннән соң, Һ.В. Йосыпов хәрәкәттәге армиягә алына. 1942 елның октябреннән ул Бөек Ватан сугышына китә, иң авыр сугыш хәрәкәтләрендә – Воронеж оборонасында, Сталинград сугышында, Курск дугасында, Көнбатыш фронтта һ. б. сержант элемтәче, разведчик булып катнаша. Курск дугасында башы яралана, контузия ала. Ул «Сталинград оборонасы өчен» һәм «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Авыр ялгануына карамастан, Һ.В. Йосыпов 1945 елның октябренә кадәр армиядә кала.

1946–1949 елларда ул – Казан университетының география факультетында өлкән лаборант, аннары атаклы Этнография музее фондында саклаучы, мөдир. Бу чорда Һ. Йосыпов экспедицияләргә чыга, музей тарихы, күренекле астроном, географ, этнограф И.М. Симоновның этнографик күзәтүләре, аның этнографик музейга нигез салган коллекциясе турында беренче фәнни мәкаләләре басыла. Шул ук вакытта Һарун Йосыпов эшчәнлегендә төп фәнни юнәлешне тәшкил иткән болгар-татар эпиграфикасын өйрәнү эше дә формалаша башлый. Гарәп палеографиясен генә түгел, ә татар халкының телен, көнкүрешен һәм мәдәниятен дә яхшы белүе аңа кыска вакыт эчендә борынгы болгар-татар эпитафияләрен уку һөнәрен төрле яклап үзләштерергә мөмкинлек бирә. 1951–1956 елларда галимнең «Эпиграфика Востока» басмаларында XIV–XVI йөзләрдәге болгар-татар эпиграфик истәлекләрен укуга, классификацияләүгә һәм фәнни аңлатуга багышланган мәкаләләре дөнья күрә.

Һ. Йосыпов 1948–1952 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантура-

да укый. Н.Ф. Калинин җитәкчелегендә Казан Кремлен археологик тикшерүдә, эпиграфик экспедицияләрдә катнаша. 1953 елда М. Ломоносов исемендәге Мәскәү университетында «XIII–XVII гасырлар болгар-татар эпиграфик ядкәрләре (Казан татарларының килеп чыгышы турындагы мәсьәләгә карата)» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Һ.В. Йосыпов 1952–1958 елларда СССР Фәннәр академиясенең Башкорт филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында археологик төркем төзеп, Башкортстанда археологик тикшеренүләрне җитәкли. Шулай итеп, Һ.В. Йосыповны Башкортстан археологиясенә нигез салучыларның берсе дип санарга мөмкин. Ул биш кыр сезоны дәвамында Агыйдел бассейнында Воскресенск, Имәндәш, Касьян һәм Табын шәһәрлекләре, Кормантау авыллыгы кебек элгәреге тимер гасырына нисбәтле үзенчәлекле археологик истәлекләрне ача һәм тикшерә. Аларны өйрәнү нәтиҗәләре «Древнейшие поселения Гафурийского района БАССР» мәкаләсендә урын алган. Һарун Йосыпов хәтта махсус археологик һәм эпиграфик экспедицияләрдә дә этнографик, шулай ук топонимика, диалектология, ономастика буенча күзәтүләр мөмкинлеген беркайчан да кулдан ычкындырмый. Параллель рәвештә ул үзенең этнография өлкәсендәге эшчәнлеген дә дәвам итә, күренекле археолог һәм этнограф С.И. Руденко белән бергә Башкортстан буенча этнографик экспедицияләрдә катнаша, анда башкорт һәм татарларның рухи мәдәнияте буенча бай материал туплый. Ул – С.И. Руденконың билгеле «Башкиры» исемле хезмәтенең рецензенты да. 50 нче еллар ахырында ук «Очерки по истории БАССР (периода феодализма)» томына «Башкортларның этногенезы турында», «Башкортстанның көнбатышында төрки халыклар турында» һ. б. гомуми характердагы мәкаләләр бастыра. Хезмәтенә башкортларның килеп чыгышы хакында бүлекчә кертә. «Көнбатыш Башкортстандагы эпиграфик ядкәрләр» дә аның төп темасы була. А. Збруева, Н. Мәҗитов һ.б. белән бергә башка тикшеренүләр алып бара. Соңрак Һ. Йосыпов Көнбатыш Башкорстандагы Тора хан, Кече мавзолей кебек археологик истәлекләрне беренчеләрдән булып тикшерә.

1960 елда, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре буларак, Һ.В. Йосыпов Мәскәүнең «Наука» нәшриятында «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» монографиясен бастыра. Ул Идел һәм Урал буендагы 200 дән артык эпиграфик һәйкәлнең беренче фәнни җыентыгын гына түгел, ә аларның беренче детальле классификациясен дә төзи. Шул рәвешле, хезмәткә төбәкнең төрки халыклары тарихы өчен дә, тел белеме өчен дә беренчел әһәмияткә ия булган гаять зур материал кертелә. Җ.Г. Мөхәммәтшин әйткәнчә, «Бу китап бүген дә тарихчы-эпиграфистларның өстәл китабы булып кала бирә». Алга таба да Һарун Вәли улы болгар-татар эпиграфик истәлекләрен эзләүдән һәм өйрәнүдән туктамый. Идел һәм Урал буеның барлык өлкәләренә дистәдән артык эпиграфик экспедицияләргә чыгып, ул XIII–XVI йөзләргә караган 600 гә якын эпитафия таба. Кызганычка каршы, галим тарихи-

лингвистик чыганакларның бу уникаль төре җыентыгын төзеп бетерә алмый. 1968 елның 20 июнендә Һарун Вәли улы Йосыпов кинәт вафат була.

Һарун Йосыпов – «Татарстан археологиясе картасы»н төзүчеләрнең дә берсе. Бу хезмәте өчен аңа вафатыннан соң, 1994 елда, башка авторлар белән берлектә, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе бирелә.

Һ. Йосыповның кызы Софья үзенең шигъри истәлекләрендә этисенең эпиграфик хезмәтен болай тасвирлый:

Пятнадцать лет, как кончилась война,
Страна считала важным – письмена!
Над вязью арабской склонилась спина,
И мокрой от пота рубаха была…

Эпиграфика белән шөгыльләнү Һ.В. Йосыповның этнографик тикшеренүләре белән бергә үрелеп бара. Аның татар халкының рухи мәдәнияте өлкәсендәге тикшеренүләре аеруча мөһим. «Наука» нәшриятында 1967 елда басылган «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» күмәк монографиясендәге кайбер мәкаләләр, шулай ук ышануларга багышланган бүлекләр беренче мәртәбә татарларның борынгы дини ышануларын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә, бу исә Идел буе татарларының рухи мәдәнияте үзенчәлекләрен ачыклау өчен генә түгел, бәлки аларның этногенезы турында фикер йөртү өчен дә яңа материал була. Һ.В. Йосыповның шул ук пландагы төрки топонимика һәм ономастика буенча хезмәтләре вафаты алдыннан языла.

Һ.В. Йосыповны белгән кешеләр аны зур галим генә түгел, армый-талмый эшләүче, үзенә һәм башкаларга таләпчән яхшы иптәш буларак та бәяли. Һ.В. Йосыпов белән эшләгән һәркем аны тыйнак һәм игелекле кеше иде дип искә ала.

Мөгаен, минем фәнгә килүем дә Һарун Вәли улы Йосыпов исеме белән дә бәйледер. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда, безнең укытучыбыз, тарих һәм филология факультеты деканы Д.Г. Тумашева, үзе җитәкчелегендә язылган курс эшләрендә рухи мәдәнияткә тартылганымны күреп, мине институтның археология бүлеге җитәкчесе, профессор А.Х. Халиков белән таныштырырга булды. А.Х. Халиков миңа күренекле эпиграфист, археолог, татар тарихи этнографиясе, рухи мәдәнияте өлкәсендә тирән эз калдырган, мин укырга кергән 1968 елны бик иртә дөнья куйган Һарун Вәли улы Йосыпов турында сөйләде. «Бу талантлы, бик тырыш галимне алыштыру бик авыр. Әмма безгә, археологларга да рухи мәдәният тарихы буенча белгеч кирәк», – диде, мине – филологны – археологик экспедицияләрдә катнашырга чакырды. Соңыннан гына аңладым: ике профессор бу хакта Һ.В. Йосыповны югалтканнан соң ук сөйләшеп куйганнар, минем тарихка, археологиягә тартылган курс эшеннән генә башланмаган икән.

Язмышка шулай язылгандыр инде: миңа институтның фәнни архивында Һ.В. Йосыповның шәхси архивын эшкәртергә, аның тасвирламасын төзергә дә насыйп булды. Бу эшне миңа кадәр эшләгән Һава Абдулла кызы Сайманова башлап җибәргән булган. Фонд бик бай һәм бик чуар, эшкәртү өчен бик катлаулы булып чыкты. Ул 4 тасвирламадан тора: 1) «Фәнни һәм башка хезмәтләре, аларга материаллар» – 630 сакл. бер.; 2) «Хезмәт, биографик, җәмәгать эшчәнлегенә караган материаллар» – 1100 эш; 3) «Башка кешеләр белән хат алышу» 996 – хат; 4) 105 эш башка кешеләргә карый. Һ.В. Йосыповның шәхси архив материаллары да аның киң кырлы галим булуын, киеренке эшчәнлеген, СССР һәм чит ил галимнәре, зыялылары, иҗади шәхесләре белән ныклы элемтәдә торуын күрсәтә.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

1. *Абдуллин Я.А., Шайдуллина Л.И.* Востоковедение в Казани // Народы Азии и Африки. 1985. № 5. С. 119–123.

2. *Гарипова З., Кабирова А.* Штрихи к портрету ученого // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2015. № 3/4, С. 202–209.

3. История. Профессия. Судьба. Памяти Мидхата Каримовича Мухарямова. Казань: Идел-Пресс, 2012.

4. *Солтанов Ф.М.* Галим һәм җәмәгать эшлеклесе: Яхъя Абдуллинның тууына 100 ел тулу уңаеннан хәтер яңарту // Из истории культуры городов Среднего Поволжья. 202. № 10. Т. 1. С. 172–178.

5. Чирек гасыр фикери эзләнүләр юлында. Казан: Школа, 2000. 124 б.

***Дәүләтшин Гамирҗан Миргаҗан улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе*

***Давлетшин Гамирзян Миргазянович,***
*доктор филологических наук,*
*заслуженный деятель науки Республики Татарстан*
*g.davletshah@mail.ru*